**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** 14.04.2021 | Казан ш. | **БОЕРЫК** 373-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2020 елның 16 апрелендәге 498-п номерлы боерыгы белән расланган Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2020 елның 16 апрелендәге 498-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2020 елның 30 ноябрендәге 1317-п номерлы боерыгы керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 бүлекнең 5.3 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Министрлыкка алынган шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы 5 эш көне эчендә»;

Регламентка 2 нче кушымтада:

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Җир асты байлыклары кишәрлегенең туры килү-килмәвен билгеләү таләпләрен үтәү (2395-1 номерлы РФ Законының 19 статьясы, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 29 статьясы) (алга таба – 1722-XII номерлы ТР Законы), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 29 февралендәге 171 номерлы карары белән расланган Җир кишәрлекләренең милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучы затлар

тарафыннан шәхси ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләре чикләрендә булган гомумтаралган файдалы казылмалардан, җир асты суларыннан файдалану, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә җир асты корылмалары төзү кагыйдәләренең (алга таба – 171 номерлы Тәртип) 3 пункты (шәхси ихтыяҗлар өчен гомумтаралган файдалы казылмалардан, җир асты суларыннан файдалану яки җир асты корылмаларын төзү нияте булганда)»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына җир асты байлыкларыннан файдалану нияте турында хәбәр итү таләпләрен үтәү (2395-1 номерлы РФ Законының 19, $19^1$ статьялары, 1722-XII номерлы ТР Законының 29 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 21 декабрендәге 1042 номерлы карары белән расланган Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә үзләренә бирелгән җир асты байлыклары кишәрлеге чикләрендә файдалы казылмаларны разведкалау һәм алуны гамәлгә ашыручы яки берләштерелгән лицензия буенча файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм алу, авыр алына торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм алу технологияләрен эшли торган яки берләштерелгән лицензия буенча авыр алына торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, мондый файдалы казылмаларны разведкалау һәм алу технологияләрен эшләүче җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан шәхси җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен расланган технологик проект нигезендә гомумтаралган файдалы казылмаларны алу тәртибенең 5 пункты, 171 номерлы Тәртипнең 6 пункты) (федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә бирелгән җир асты байлыклары кишәрлеге чикләрендә шәхси җитештерү һәм технологик ихтыяҗлар өчен гомумтаралган файдалы казылмаларны алу очрагында)»;

Регламентка 3 нче кушымтада:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. РФ Җир кодексы һәм «Махсус сакланыла торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – 33-ФЗ номерлы Федераль закон) башкасы каралмаган булса, федераль мөлкәттәге дәүләт табигый тыюлыклары һәм милли парклар урнашкан җир кишәрлекләрен әйләнештән алу (Россия Федерациясе Җир кодексының 27 статьясындагы 4 пункты)»;

3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- РФ Җир кодексының 27 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелмәгән махсус сакланыла торган табигый территорияләр чикләрендә, әгәр РФ Җир кодексы һәм махсус сакланыла торган табигать территорияләре турындагы Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса»;

4 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-33-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, махсус сакланыла торган табигать территорияләре, шул исәптән махсус сакланыла торган

табигать территорияләре өчен резервланган (РФ Җир кодексының 95 статьясындагы 3, 5, 7 пунктлары, 7-ФЗ номерлы Федераль законның 58 статьясының 4 пункты, 59 статьясының 2 пункты, 33-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 1 пункты, 21 статьясының 4 пункты, 24 статьясының 1 пункты, 27 статьясының 1 пункты, 29 статьясының 1 пункты)»;

җиденче абзацта «04.12.2006 ел, № 200-ФЗ» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.И.Ткачук) әлеге боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М.Шиһаповка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков